РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН СОВЕТ БИЗЯКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МЕНДЕЛЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БӘЗӘКӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

ИНН 1627005514 ОГРН 1061674006789
423648 с. Бизяки, ул. Центральная, д.46 Тел. (факс): (85549) 3-47-34 e-mail: Bzk.Men@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**№15** **11.02.2026**

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы «Бәзәкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге муниципаль вазыйфасын биләүче затка карата үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр тапшырган өчен, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, әгәр әлеге белешмәләрне бозып күрсәтү җитди булмаса, җаваплылык чаралары куллану турында карар кабул итү тәртибе

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 29 статьясындагы 5 өлеше нигезендә, «Контракт буенча муниципаль вазыйфаларны, җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм затлар, контракт буенча муниципаль вазыйфаларны, җирле администрация башлыгы вазыйфаларын биләүчеләр тарафыннан тапшырылган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү турында” 2017 елның 19 июлендәге 57-ТРЗ номерлы закон, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы " Бәзәкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы белән, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлеге Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы « Бәзәкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге муниципаль вазыйфасын биләүче затка карата үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр тапшырган өчен, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, әгәр әлеге белешмәләрне бозып күрсәтү җитди булмаса, җаваплылык чаралары куллану турында карар кабул итү тәртибен расларга. (Кушымта).
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында http://mendeleevsk.tatarstan.ru « Бәзәкә авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга

Бәзәкә авыл җирлеге Советы рәисе И.И. Кәшәфетдинов

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Бәзәкә авыл җирлеге Советының
2026 елның 11 февралендәге 15
нче номерлы карарына кушымта

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы « Бәзәкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге муниципаль вазыйфасын биләүче затка карата үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр тапшырган өчен, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, әгәр әлеге белешмәләрне бозып күрсәтү җитди булмаса, җаваплылык чаралары куллану турында карар кабул итү ТӘРТИБЕ

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы " Бәзәкә авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге муниципаль вазыйфасын биләүче затка карата үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр тапшырган өчен, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, әгәр әлеге белешмәләрне бозып күрсәтү җитди булмаса, җаваплылык чаралары куллану турында карар кабул итү тәртибен 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 29 статьясындагы 4 өлешендә каралган җаваплылык чаралары белән билгели (алга таба — тәртип).

2. Муниципаль вазыйфаны биләүче затка карата үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр тапшырган өчен, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, әгәр әлеге белешмәләрне бозып күрсәтү җитди булмаса, түбәндәге җаваплылык чаралары кулланылырга мөмкин:

1) кисәтү;

2) муниципаль вазыйфаны биләүче затны, вәкаләтләре чоры туктатылганчы, тиешле җирле үзидарә органындагы вазыйфасыннан мәхрүм итеп, азат итү;

3) вәкаләтләре чоры туктатылганчы вәкаләтләрне даими нигездә башкару хокукыннан мәхрүм итеп, вәкаләтләрне гамәлгә ашырудан азат итү;

4) җирле үзидарәнең тиешле органындагы вазыйфаларны аның вәкаләтләре чоры туктатылганчы биләүне тыю;

5) вәкаләтләрне үз вәкаләтләре чоры туктатылганчы даими нигездә башкаруны тыю.

3. Муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга карата әлеге Тәртипнең 2 пунктында санап үтелгән җаваплылык чараларының берсен куллану турындагы мәсьәлә Бөрешле авыл җирлеге Советы (алга таба – Совет) тарафыннан карала.

Күрсәтелгән мәсьәләне карау өчен нигез булып муниципаль вазыйфаны биләүче затка карата җаваплылык чараларын куллану турында Татарстан Республикасы Башлыгының (Рәисенең) советка кергән гаризасы тора.

4. Татарстан Республикасы Башлыгының (Рәисенең) җаваплылык чараларын куллану турындагы гаризасы Совет тарафыннан әлеге гариза әлеге органга кергән көннән алып 30 көннән дә соңга калмыйча карала. Җаваплылык чараларын куллану турында Карар кабул итәргә вәкаләтле Совет эшенең төп рәвеше сессияләр һәм Татарстан Республикасы Башлыгының (Рәисенең) җаваплылык чараларын куллану турындагы гаризасы сессияләр арасындагы чорда кергән очракта, күрсәтелгән гариза ул кергән көннән өч айдан да соңга калмыйча карала.

5. Совет муниципаль вазыйфаны биләүче затка күрсәтелгән мәсьәләне карау датасына кимендә биш эш көне кала язма рәвештә аңа карата җаваплылык чаралары куллану турындагы мәсьәләне карау турында хәбәр итә.

Муниципаль вазыйфаны биләүче затның совет утырышы урыны һәм вакыты турында хәбәр ителгән вакытка килмәве Татарстан Республикасы Башлыгының (Рәисенең) җаваплылык чараларын куллану турындагы гаризасын карарга комачауламый.

6. Татарстан Республикасы Башлыгының (Рәисенең) муниципаль вазыйфаны биләүче затка карата җаваплылык чараларын куллану турындагы гаризасы Совет утырышында карала.

Күрсәтелгән мәсьәлә каралганда муниципаль вазыйфаны биләүче затка тапшырылган белешмәләр буенча аңлатмалар бирү мөмкинлеге бирелергә тиеш.

7. Татарстан Республикасы Башлыгының (Рәисенең) гаризасын карау нәтиҗәләре буенча җаваплылык чарасын куллану турында йә җаваплылык чарасын куллanудан баш тарту турында Карар кабул ителә.

Татарстан Республикасы Башлыгының (Рәисенең) гаризасы кергән Депутат тавыш бирүдә катнашмый.

8. Җаваплылык чарасын куллану турындагы карар гаделлек, тигезлек, пропорциональлек һәм котылгысызлык принциплары нигезендә, кылынган коррупциячел хокук бозуның характерын, аның авырлыгын, ул башкарылган шартларны исәпкә алып, шулай ук муниципаль вазыйфаны биләүче затның үз вазыйфаи бурычларын (вәкаләтләрен) үтәвенең алдагы нәтиҗәләрен, башка чикләүләрне, тыюларны һәм бурычларны үтәвен исәпкә алып кабул ителә.

Хисап чорында керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр тапшырган өчен бер генә җаваплылык чарасы кулланылырга мөмкин.

9. Җаваплылык чарасын куллану турындагы карарда коррупциячел хокук бозуга күрсәтмә, муниципаль вазыйфаны биләүче зат тарафыннан бозылган норматив хокукый актлар нигезләмәләре, карарга карата Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә шикаять белдерү хокукы булырга тиеш.

10. Җаваплылык чарасын кулланудан баш тарту турындагы карарда мондый баш тартуның дәлилләнгән нигезләмәсе булырга тиеш.

11. Җаваплылык чарасын куллану турында яисә җаваплылык чарасын кулланудан баш тарту турындагы карарның күчермәләре ул кабул ителгән көннән алып биш эш көне эчендә муниципаль вазыйфаны биләүче затка кул куеп тапшырыла йә тапшыру турында хәбәр белән почта аша җибәрелә, шулай ук Татарстан Республикасы Башлыгына (Рәисенә) җибәрелә.

Әгәр җаваплылык чарасын куллану турындагы карарны муниципаль вазыйфаны биләүче затка җиткерү мөмкин булмаса яисә күрсәтелгән зат имза салып карарны кабул итүдән баш тартса, совет рәисе югарыда күрсәтелгән затның җаваплылык чарасын куллану турындагы яисә мондый карар турында аңа хәбәр итү мөмкин булмау турындагы карар белән таныштырудан баш тарту хакында акт төзи.

12. Җаваплылык чарасын куллану яисә җаваплылык чарасын кулланудан баш тарту турындагы карарга Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә шикаять белдерелергә мөмкин.